| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.04.2021 г.Казань № 2

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 11 маеда 7668 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2021 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ инвалидларны һәм гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланырга тиешле эш урыннары санын билгеләү турында» 2020 елның 7 сентябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 4 маендагы 170 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2021 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ инвалидларны һәм гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланырга тиешле эш урыннары санын билгеләү турында» 2020 елның 7 сентябрендәге 2 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

2021 елның 1 мартындагы 1 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «850» саннарын «846» саннарына алмаштырырга;

1 нче кушымтада:

1 пунктның 4, 5, 7 һәм 9 пунктларында саннар «11466», «897», «43», «266» саннарын, туры китереп, «11302», «886», «42», «262» саннарына алмаштырырга;

6 пунктны көчен югалткан дип танырга;

234 пунктны көчен югалткан дип танырга.

2. «Авиатөзелеш районы Халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ, «Теләче районы Халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директорларына әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көнлек срокта, үзләренә карата 2021 елга инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләнгән квоталар үзгәрү сәбәпле, эш бирүчеләргә язмача хәбәр итәргә.

3. Әлеге карар үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары К.А.Таҗетдиновага йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова